**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в состав Межведомственной комиссии по экологической безопасности, природопользованию и санитарно-эпидемиологическому благополучию в Республике Татарстан

1. Внести в состав Межведомственной комиссии по экологической безопасности, природопользованию и санитарно-эпидемиологическому благополучию в Республике Татарстан (далее – Комиссия), утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 27 сентября 2012 года № УП-786 «О Межведомственной комиссии по экологической безопасности, природопользованию и санитарно-эпидемиологическому благополучию в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 13 марта 2014 года № УП-271, от 28 марта 2015 года № УП-372, от 14 ноября 2015 года № УП-1094, от 16 июня 2017 года № УП-505 и от 14 мая 2018 года № УП-370), следующие изменения:

а) вывести из состава Комиссии Д.Г. Калинкина, А.Р. Салихова, И.Р. Сафиуллина, И.Э. Файзуллина, Н.Н. Хабипова, Т.Г. Хадеева, Ф.Ю. Хайрутдинова;

б) ввести в состав Комиссии:

Айзатуллина Марата Мансуровича – министра строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан;

Галеева Ильнура Наиловича – руководителя Управления Федеральной службы по ветеринарному и фитосанитарному надзору по Республике Татарстан (по согласованию);

Гафарова Рустема Гильфановича – руководителя Исполнительного комитета муниципального образования города Казани (по согласованию);

Коробченко Екатерину Владимировну – заместителя начальника отдела по вопросам использования недр, природных ресурсов и охраны окружающей среды Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан;

Минушева Тимура Рустемовича – начальника управления экономической безопасности и противодействия коррупции Министерства внутренних дел по Республике Татарстан (по согласованию);

Хамаева Азата Киямовича – председателя Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по экологии, природопользованию, агропромышленной и продовольственной политике (по согласованию);

Ханбикова Ильшата Шарибзяновича – заместителя руководителя – начальника отдела водных ресурсов по Республике Татарстан Нижне-

Волжского бассейнового водного управления Федерального агентства водных ресурсов (по согласованию);

Шакирова Фаяза Фаниловича – руководителя Волжско-Камского межрегионального управления Федеральной службы по надзору в сфере природопользования (по согласованию);

в) изложить наименование должности члена Комиссии С.Д. Захарова в следующей редакции: «начальник федерального государственного бюджетного учреждения «Управление по гидрометеорологии и мониторингу окружающей среды Республики Татарстан» (по согласованию)».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
09 апреля 2022 года
№ УП-257

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия турында» 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 13 мартындагы ПУ-271 номерлы, 2015 елның 28 мартындагы ПУ-372 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1094 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге ПУ-505 номерлы һәм 2018 елның 14 маендагы ПУ-370 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Д.Г. Калинкинны, А.Р. Салиховны, И.Р. Сафиуллинны, И.Ә. Фәйзуллинны, Н.Н. Хәбиповны, Т.Г. Һадиевны, Ф.Ю. Хәйретдиновны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Айзатуллин Марат Мансур улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Галиев Илнур Наил улын – Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Гаффаров Рөстәм Гыйльфан улын – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Коробченко Екатерина Владимировнаны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигать ресурсларыннан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасарын;

Минушев Тимур Рөстәм улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәшү идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Хамаев Азат Кыям улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисен (килешү буенча);

Ханбиков Илшат Шәрипҗан улын – Су ресурслары федераль агентлыгының Түбән Идел бассейны су идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге башлыгын (килешү буенча);

Шакиров Фаяз Фәнил улын – Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзасы С.Д. Захаровның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 09 апрель
№ ПУ-257